СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

21.12.2021 Әгерҗе ш. № 14-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге уставында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмә;

- Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өчен төп күрсәткечләр, анық максатчан күрсәткечләре һәм автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өчен индикатив күрсәткечләр.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 28 сентябрендәге 11-2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип

танырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының шәһәр төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык, транспорт һәм элемтә буенча «Әгерже шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының даими комиссиясенә (Башаров Р.Р.) йөкләргә.

Совет рәисе
муниципаль берәмлек башлыгы Ә.Р. Вәлиев